РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07.11.2019** г.Кукмор **№ 617**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 һәм 17 маддәләре, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 9 һәм 37 маддәләре нигезендә һәм Кукмара муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклландыруны оештыру тәртибе турында кушымта Нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә)

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклландыруны оештыру турында» 2019 елның 21 гыйнварындагы 60 нчы номерлы карары (алга таба – 60 нчы номерлы карар) үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына (алга таба – гомуми белем бирү оешмалары):

- әлеге карарны үзенең мәгълүмати стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырырга;

- гомуми белем бирү оешмалары укучыларының ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында гомуми белем бирү оешмаларының гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчасы исәбеннән туклану (алга таба – ташламалы туклану) хокукын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә нигезендә аңлату эшләре алып барырга;

- Нигезләмә таләпләрен үтәп, гомуми белем бирү оешмасында укучыларны тукландыруны оештыруны тикшереп тору һәм гомуми белем бирү оешмасында укучыларны ташламалы тукландыруны тәэмин итү буенча комиссияләр (алга таба – комиссияләр) төзергә һәм аларның эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тудырырга;

- Нигезләмә таләпләрен үтәү максатларында башка чаралар күрергә.

5. Билгеләргә:

- ташламалы туклану белән әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә, әгәр 60 нчы номерлы карар нигезендә ташламалы туклану бирү өчен нигезләр юкка чыкмаган булса; әлеге карар үз көченә кергән датага 60 нчы Карар нигезендә ташламалы туклану алган укучылар категорияләре тәэмин ителүне дәвам итәләр;

- әлеге карар үз көченә кергән датага карата 60 нчы Карар нигезендә ташламалы туклану алган һәм ташламалы туклану турында гаризаны карау йомгаклары буенча ташламалы тукландыруны бирүдән баш тарту турында комиссия карары кабул ителгән көнгә кадәр нигезләмә нигезендә ата-анасы (законлы вәкил) ташламалы туклану турында гариза белән гомуми белем бирү оешмасына мөрәҗәгать иткән гомуми белем бирү оешмасы укучысы, мондый гариза әлеге карар үз көченә кергән көннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча гомуми белем бирү оешмасына бирелгән очракта, ташламалы туклану белән тәэмин ителә.

6. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (Мансуров Р. М.):

- әлеге карарны тормышка ашыруда гомуми белем бирү оешмаларына кирәкле ярдәм күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф Идарәсе тарафыннан нигезләмәдә каралган тиешле функцияләрне (вәкаләтләрне) оештыруны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

7. Кукмара муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (И.К.Сәмигуллин) Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан нигезләмәдә каралган тиешле функцияләрне (вәкаләтләрне) гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

8. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru).урнаштырган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесенең вазыйфаларын башкаручы Ч.Г. Ханафина**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының
«___» ________ 201___ ел № ________
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында**
**Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары (алга таба – районның гомуми белем бирү оешмалары) укучыларын тукландыруны оештыру турында әлеге Нигезләмә, әлеге оешмаларның укучыларын тукландыруны оештыру процессын җайга салу, мондый укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына районның гомуми белем бирү оешмалары укучыларына өстәмә социаль ярдәм максатларында эшләнде.

1.2. Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм, Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «СанПиН 2.4.5.2409-08 раслау турында» (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 07.08.2008 № 12085 белән теркәлгән) (алга таба – СанПиН 2.4.5.2409-08) 2008 елның 23 июлендәге 45 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.4.5.2409-08 СанПиНны исәпкә алып, һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – ТР Законы № 63-ТРЗ) нигезендә эшләнгән.

- Министрлыкның территориаль органы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы;
- Башкарма комитет – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;
- Мәгариф идарәсе – Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;
- гомуми белем бирү оешмасы администрациясе – район гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе һәм (яки) район гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасары;
- ташламалы туклану – әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән затларны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре хисабына агымдагы елда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруга 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган акчалата түләү күләменнән артып киткән сумма өлешендә (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының хокукый акты нигезендә ел саен индексацияне исәпкә алып), туклandыруны тәэмин итү;

- ЕГИССО – «Дәүләт социаль ярдәме турында» 17.07.1999 ел, 178-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә төзелә торган Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (Единая государственная информационная система социального обеспечения);

- балага айлык пособие – 63-ТРЗ номерлы Закон нигезендә 16 яшькә кадәрге балага түләнә торган айлык пособие (гомуми белем бирү оешмасында укучы балага – уку тәмамланганчы, әмма ул 18 яшькә җиткәнче генә);

- оешмалардан мәгълүмат бирү турында сорату – дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә, башка оешмаларга җибәрелә торган кәгазьдә яисә электрон документ формасындагы гариза бирүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән документларның һәм мондый документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат тапшыру турында документ;

- ЕГИССОдан мәгълүмат бирү турындагы сорату – гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларның һәм мондый документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү максатларында җибәрелә торган ЕГИССОда булган мәгълүматны бирү турында сорату;

- комиссия – районның гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклandыруны оештыруны тикшереп тору һәм районның гомуми белем бирү оешмасында укучыларны льготалы туклandыруны тәэмин итү буенча районның гомуми белем бирү оешмаларында төзелә торган комиссия. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктындагы дүртенче абзацында каралган очракта, ташламалы туклану турындагы гаризаларны карау өлешендә комиссиянең функцияләре (вәкаләтләре) Мәгариф идарәсе акты белән билгеләнә торган комиссия тарафыннан башкарыла;

- укучылар – районның гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми яки урта гомуми белем бирү программаларын, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче затлар;

- гариза бирүчеләр – балигъ булмаган балаларның районның гомуми белем бирү оешмасына ташламалы туклану турында гариза белән мөрәҗәгать итүче ата-аналары (законлы вәкилләре);

- мәнфәгатьләр каршылыгы – кандидатурасы комиссия составына кертү өчен карала торган яки комиссия составына кертелгән физик затның шәхси (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынуы аны комиссия составына кертү (комиссия составына кертү белән бәйле вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) белән бәйле функцияләрне тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яки тәэсир итәргә мөмкин булган хәл;

- шәхси кызыксыну – әлеге пунктның ундүртенче абзацында күрсәтелгән зат һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта яисә кардәшлектә торучы затлар (ата-аналары, ирләре-хатыннары, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, шулай ук ир-хатынның абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары, балалары, балаларының ир-хатыннары), гражданнар яисә әлеге пунктның ундүртенче абзацында күрсәтелгән зат яки аның белән якын туганлыкта яисә кардәшлектә торучы затлар милек, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйле булган оешмалар тарафыннан акча, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокук, милек характерындагы хезмәт күрсәтү, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яки нинди дә булса файда (өстенлекләр) рәвешендә керем алу мөмкинлеге.

1.4. Укучыларны тукландыруны оештыруның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: туклануның һәркем өчен мөмкин булуын һәм сыйфатын арттыру, ата-аналар (законлы вәкилләр) һәм 63-ТРЗ номерлы ТР Законы нигезендә бирелә торган социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру (түләүләрне гамәлгә ашыру) хисабына укучыларны тукландыруны арттыру, ташламалы туклануны тәэмин итү, заманча технологияләр таләпләре нигезендә районның гомуми белем бирү учреждениеләренең азык-төлек блогын камилләштерү, сәламәт һәм тулы кыйммәтле туклану принципларын пропагандалау.

**II. Районның гомуми белем бирү оешмаларында туклануны оештыру. Комиссия вәкаләтләре. Ташламалы туклану хокукына ия укучылар**

2.1. Азык-төлек продуктлары һәм азык-төлек чималы белән тәэмин итүче юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (физик затлар) һәм районның гомуми белем бирү оешмалары арасында үзара мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә төзелә торган шартнамә белән җайга салына.

2.2. Туклануны оештыручы районның гомуми белем бирү оешмасы ашханәсендә түбәндәге таләпләрнең үтәлеше тәэмин ителергә тиеш:

- ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру;
- квалификацияле кадрлар булу;
- һәр хезмәткәрнең шәхси медицина кенәгәләре булу;
- хезмәткәрләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә алдан, эшкә кергәндә һәм периодик медицина тикшерүләрен, һөнәри гигиеник әзерлек һәм аттестация узулары;
- кулинария әйберләренең (ризыкның) технологик карталары булу;
- Саба, Мамадыш, Кукмара, Теләче районнарында район гомуми белем бирү оешмасы директоры тарафыннан расланган һәм кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлеге белән килештерелеп эшләнгән үрнәк менюның булуы;
- азык-төлек продуктларын һәм азык-төлек чималын кабул итү бары тик тиешле документлар (мәсәлән, азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы таныклыклары, ветеринария-санитария экспертизасы документлары, азык-төлек продуктларын җитештерүче һәм тәэмин итүченең продуктларның килеп чыгышын раслый торган документлары, ярашлылык сертификаты, ярашлылык турында декларацияләр), азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә азык-төлек продуктларының билгеле бер партиясенә керүен раслый торган документлар булганда гына;
- СанПиН 2.4.5.2409-08 дә күрсәтелгән азык-төлек продуктларын куллануга, ашамлыклар һәм аш-су әзерләүгә чикләүләрне үтәү;
- законнарда каралган башка таләпләр.

2.3. Гомуми белем бирү оешмасы ашханәсенең эшен администрация (гомуми белем бирү оешмасы директоры, муниципаль гомуми белем бирү оешмасы директоры урынбасарлары) һәм комиссия контрольдә тота.

2.4. Гомуми белем бирү оешмасының ашханә эшен контрольдә тоту тәртибендә Комиссиянең хокуклары:

- районның гомуми белем бирү оешмасы медицина хезмәткәре белән берлектә районның гомуми белем бирү оешмасына китерелә торган азык-төлек

продуктларының һәм азык-төлек чималының законнар нигезендә мәҗбүри таләпләргә һәм шартнамә шартларына туры килүен тикшерү;

- районның гомуми белем бирү оешмасында махсус саклау шартларын таләп итүче тиз бозыла торган азык-төлек продуктларын саклау шартлары һәм сроклары үтәлүне контрольдә тотуны, термометрлар ярдәмендә суыткыч җиһазында температура режимнарын контрольдә тотуны тормышка ашыру;

- районның гомуми белем бирү оешмасында журнал, ведомостьлар булуны һәм 2.4.5.2409-08 СанПиНда каралган башка документларның һәм аларның дөрес алып барылуын контрольдә тоту (рәсмиләштерү);

- гомуми белем бирү оешмасында азык-төлек блогының һәм төшке аш залының (азык-төлек продуктларын саклау, ашарга тарату һәм кабул итү, ашханә савыт-сабасын юу өчен билгеләнгән аерым бүлмәләрнең) санитар торышын тикшереп тору;

- районның гомуми белем бирү оешмаларында сатыла торган ризыкларның расланган менюга туры килүен тикшерү;

- ачыкланган хокук бозуларны (җитешсезлекләрне) бетерү буенча, укучыларның туклануын камилләштерү буенча тәкъдимнәрне районның гомуми белем бирү оешмасы директорына җибәрү.

2.5. Укучыларның туклануын оештыруны тикшереп торудан тыш, уку елы башында һәм кирәк булган саен комиссия түбәндәгеләрне башкара:

- гариза бирүчеләрдән гаризалар кабул итә һәм карый;

- ташламалы туклану бирү яки ташламалы тукланудан баш тарту турында Карар кабул итә;

- укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) мөрәҗәгатьләре, дәүләт органнарыннан, дәүләт учреждениеләреннән, җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль учреждениеләрдән һәм башка оешмалардан, районның гомуми белем бирү оешмасы администрациясеннән кергән мәгълүматлар нигезендә ташламалы туклану бирүне туктату турындагы мәсьәләне карый;

- мәгълүмат бирү турында оешмалардан соратулар җибәрергә хокуклы;

- оешмалардан, ЕГИССОдан мәгълүмат бирү турында соратулар җибәрү кирәклеге турында язмача тәкъдимнәр белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

- гаиләнең аз керемле тәэмин ителеше турындагы әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында каралган шартны билгеләү максатларында, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт яисә муниципаль учреждениеләргә ташламалы туклану бирү турында гариза һәм аңа кушып бирелгән документларны тапшырырга хокуклы;

- киләсе ай (хисап ае) дәвамында ташламалы туклану хокукына ия булган укучылар исемлеген хисап аеннан алдагы айның 25 нче числосыннан да соңга калмыйча раслый; кирәк булган очракта, мондый исемлекләрдәге үзгәрешләрне раслый; исемлекләрне (исемлектәге үзгәрешләрне) районның гомуми белем бирү оешмасы һәм ашханәсе, район гомуми белем бирү оешмасының тиешле хезмәткәрләре игътибарына җиткерә.

2.6. Дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, андый гаиләләр аз тәэмин ителгән очракта, ташламалы туклану хокукына ия.

Әлеге Нигезләмәдә аз тәэмин ителгән дип җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе Татарстан Республикасы № 63-ТРЗ

Законына кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаилә таныла.

Җан башына уртача керем исәплəгəндə исәпкə алына торган гаилә составы, җан башына уртача керем исәплəгəндə исәпкə алына торган керем төрләре, җан башына уртача керем исәплəгəндə исәпкə алынмый торган керем төрләре, җан башына уртача керем күләмен исәпләү, гаиләнең җан башына уртача керемен исәплəгəндə аерым керем төрләрен исәпкə алу үзенчәлекләре «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү Тәртибендә булган тиешле таләпләргә (нигезләмәләргә) охшаш рәвештә исәпкә алына (билгеләнә).

2.7. Конкрет укучыны (конкрет укучыларны) ташламалы тукландыруга нигез булып ташламалы туклану турындагы беркетмә рәвешендәге комиссия карары тора.

2.8. Ташламалы туклану бирү турындагы карар әлеге карар кабул ителгән бер уку елы дәвамында гамәлдә була, ләкин шул ук вакытта гариза бирүче тарафыннан аның нигезендә гариза бирүче балага айлык пособие алучы булып торганлыгы турында Министрлыкның территориаль органы карары (белешмәсе) бирелгән очракта, ташламалы туклану бирү турындагы карарның гамәлдә булу вакыты мондый пособие билгеләнгән көннән алты айдан артмаска тиеш (мондый пособие билгеләнгән башка срок).)

2.9. Әгәр мөрәҗәгать итүче районның гомуми белем бирү оешмасына әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы унберенче абзацы нигезендә Министрлыкның территориаль органы карарын (белешмә) тапшырган булса, ташламалы туклану бирү түбәндәге нигезләрнең берсе булса да туктатыла:

- балага айлык пособие билгеләнгән көннән соң алты ай вакыт узу (балага айлык пособие билгеләнгән башка срок);

- Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау Министрлыгыннан һәм (яки) Министрлыкның территориаль органыннан гариза бирүчегә балага айлык пособие түләүне туктату яки гомуми белем бирү оешмасына мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителгән территориаль орган карарында (белешмәдә) мәгълүматларның дөрес булмавы турында язмача мәгълүмат керү;

- гариза бирүчегә балага айлык пособие билгеләү турында ЕГИССОда мәгълүмат булмавы; ЕГИССОда гариза бирүчегә балага айлык пособие түләвен туктату һәм (яисә) территориаль орган карарындагы (белешмәдәге) гариза бирүче тарафыннан районның гомуми белем бирү оешмасына тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавы турында мәгълүмат булу.

Әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында каралган нигезләрдән тыш, комиссиянең ташламалы туклануны туктату турында карары нигезендә ташламалы туклану бирү туктатыла.

2.10. Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, комиссия ташламалы туклануны туктату турында Карар кабул итә:

- гаиләнең аз тәэмин ителгәнлеге турында әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында каралган шартның булмавын ачыклау, ташламалы туклану бирүне туктатуга китерә торган башка шартларны ачыклау;

- ташламалы туклану бирүнең хокуксызлыгын ачыклау, шул исәптән ялган мәгълүматлы документлар тапшыру, ташламалы туклану алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү, хисап хаталары нәтиҗәсендә.

2.11. Районның гомуми белем бирү оешмаларында ташламалы туклану уку көннәрендә бирелә.

## III. Комиссияне формалаштыру тәртибе. Комиссия эшен оештыру

3.1. Комиссия район гомуми белем бирү оешмасы администрациясе, районның гомуми белем бирү оешмасының педагогик, медицина һәм (яки) башка хезмәткәрләре, балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасыннан төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

Комиссия составы мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү өчен төзелә.

Комиссия составы районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең локаль акты белән раслана.

Комиссия даими (әмма кварталга 1 тапкырдан да ким түгел) районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе каршындагы киңәшмәдә, инструктив-методик киңәшмәләрдә, районның гомуми белем бирү оешмаларының педагогик Советында аңа бирелгән йөкләмәләрне үтәү һәм контрольдә тоту буенча эш турында хисап тота.

3.2. Комиссия утырышына чыгарылган мәсьәләне караганда, комиссия әгъзасы булган зат мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында комиссия рәисенә (комиссия рәисе урынбасарына) хәбәр итәргә тиеш.

Комиссия утырышына чыгарылган мәсьәләне караганда, районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе булмаган комиссия рәисе (комиссия рәисе урынбасары) мәнфәгатьләр каршылыгы булуы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш.

Комиссия утырышына чыгарылган мәсьәләне караганда, районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе булган комиссия рәисе (комиссия рәисе урынбасары) мәнфәгатьләр каршылыгы булуы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында Мәгариф идарәсе җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш.

3.3. Комиссия рәисе (комиссия рәисе урынбасары), комиссия әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында дөрес мәгълүмат булган очракта, комиссия тарафыннан тиешле мәсьәләне караганда, мондый комиссия әгъзасын комиссия эшенә катнаштырмый.

Районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе, район гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе булмаган комиссия рәисенең (комиссия рәисе урынбасарының) мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында дөрес мәгълүмат булган очракта, комиссия тарафыннан тиешле мәсьәләне караганда, комиссия рәисен (комиссия рәисе урынбасарын) комиссия эшенә катнаштырмый. Бу

очракта комиссия рәисе (Комиссия рәисе урынбасары) функцияләре районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең локаль акты белән башка затка йөкләнә.

Әгәр комиссия әгъзаларының комиссия эшенә юл куймау әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы беренче абзацы нигезендә билгеләнгән кворумның булмавына китерә икән, районның гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе үз акты белән әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты таләпләренә туры килә торган башка затларны комиссия составына кертә.

Мәгариф идарәсе җитәкчесе район гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе булган комиссия рәисендә (комиссия рәисе урынбасарында) мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында дөрес мәгълүмат булган очракта, комиссия тарафыннан тиешле мәсьәләне караганда, район гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесен комиссия эшенә катнаштырмый. Бу очракта комиссия составы тулысынча мәгариф идарәсе акты белән билгеләнә. Мәгариф идарәсе акты белән билгеләнә торган Комиссия ташламалы туклану турында беренчел гариза бирелгән районның гомуми белем бирү оешмаларында укучы балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре), педагогик, медицина һәм (яки) районның гомуми белем бирү оешмаларының башка хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Мәгариф идарәсе акты белән билгеләнә торган комиссия составына башка затлар да кертелергә мөмкин. Мәгариф идарәсе акты белән билгеләнә торган комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш. Әлеге абзацта күрсәтелгән комиссияне формалаштыру турында мондый комиссия оешкан көннән бер эш көне дәвамында ташламалы туклану турында беренчел гариза бирелгән гомуми белем бирү оешмасына хәбәр итә.

Әлеге пунктның дүртенче абзацы нигезендә төзелгән комиссия составы вакытлыча: ташламалы туклану турында конкрет гаризаны карау өчен.

3.4. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашкан очракта хокуклы дип санала.

Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Утырышта катнаша алмаучы комиссия әгъзаларының утырыш башланганчы кергән язма рәвештәге фикере тавышларны санаганда исәпкә алына.

Комиссия карары комиссия утырышында катнашкан һәм әлеге бәяләмәне кабул итү өчен тавыш биргән барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган комиссия утырышы беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсенә комиссия әгъзаларының язма рәвештә тәкъдим ителгән фикере теркәлә.

## IV. Ташламалы туклану турында гаризаларны карау тәртибе

4.1. Гариза бирүчеләр яки гариза бирүчеләрнең ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле затлары, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә, районның гомуми белем бирү оешмасына ташламалы туклану бирү турында гариза тапшыралар.

4.2. Гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

- гариза бирүченең аның шәхси мәгълүматларын, балигъ булмаган баласының мәгълүматларын әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә эшкәртүгә язма ризалыгы;

- Министрлыкның территориаль органы тарафыннан ата-аналарның (уллыкка алучыларның) берсенә бирелә торган күп балалы гаилә таныклыгының күчермәсе;

- гариза бирүченең паспорт күчермәсе яисә гариза бирүченең закон нигезендә шәхесен таныклаучы башка документның күчермәсе;

- гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган, ташламалы туклану бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган документлар;

- гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары милкендә булган күчемсез милек объектларына хокук билгеләүче документлар;

- әгәр комиссиягә ташламалы туклану турында гариза бирелгән район гомуми белем бирү оешмасында ачылган шәхси эштә (шәхси эшләрдә), андый күчермәләре юк икән, гариза бирүченең гаилә составы турындагы документларның (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында Карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.) күчермәләре;

- әгәр гаиләдә Россия Федерациясе Торак кодексының 51 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр төре белән интегүчеләр бар икән, закон нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган очракта (Халыкара статистик классификация буенча авыру кодын һәм сәламәтлек белән бәйле проблемаларны күрсәтеп (унынчы тапкыр яңадан карау)), гаилә әгъзасында, закон нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаса, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр төре булу турында медицина оешмасыннан белешмәнең төп нөсхәсе;

- аңа карата ташламалы туклану турында гариза бирелә торган укучының яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны турында мәгълүмат булган документы;

- гариза гариза бирүчеләр исеменнән башка зат (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан бирелгән очракта – ышаныч кәгазе.

Әлеге пунктның бишенче, алтынчы һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән документларны тапшыру урынына гариза бирүчеләр яисә гариза бирүченең ышанычнамә нигезендә вәкаләтле затлары Министрлыкның территориаль органының аның нигезендә гариза бирүче балага айлык пособие алучы булып торуын дәлилли торган карарын (белешмә) тапшырырга хокуклы;

Гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре (медицина оешмасыннан бирелгән белешмәләрдән тыш) тапшырыла. Документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма) тарафыннан расланмаган очракта, алар карау өчен бирелгән документның төп нөсхәсе белән тәкъдим ителә һәм гариза бирелә торган районның гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәре тарафыннан раслана.

4.3. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар теркәлгәннән соң бер эш көне дәвамында районның гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан карап тикшерү өчен комиссиягә җибәрелә.

4.4. Район мәгариф идарәсе акты белән комиссия формалаштырганда районның гомуми белем бирү оешмасы түбәндәгеләрне башкара:

- әлеге комиссия төзелгәннән соң ике эш көне дәвамында Мәгариф идарәсенә гариза һәм аңа кушып бирелгән документларны җибәрә;

- гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны Мәгариф идарәсенә

җибәрү турында ике эш көне дәвамында гариза бирүчегә язмача хәбәр итә;

4.5. Гаризаны карау һәм комиссия карарын кабул итү вакыты: комиссиягә гариза кергән көннән соң 20 көннән дә артык түгел.

гаризаны карау срогы Комиссия гариза бирүчеләр тапшырган документларның һәм андый документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү максатларында, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны һәм мондый документлардагы белешмәләрне өстәмә тикшерү максатларында, Башкарма комитетка дәүләт органнарыннан, дәүләт учреждениеләреннән һәм башка оешмалардан мөрәҗәгатьләр кирәклеге турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән очракта Комиссия карары белән озайтыла. Мондый озайту срогы комиссиягә гариза кергән көннән соң 50 көннән дә артмаска тиеш.

4.6. Комиссия, түбәндәге нигезләрнең берсе булса да, ташламалы туклану бирүдән баш тарту турында Карар кабул итә:

а) әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм (яисә) әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау. Шул ук вакытта, әгәр әлеге документлар шушы Нигезләмәнең 1 нче һәм 2 нче кушымталары нигезендәге формалар буенча рәсмиләштерелмәгән (төзелмәгән) булса, гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын, балигъ булмаган баласының мәгълүматларын эшкәртүгә гариза һәм язма ризалыгы тапшырылмаган дип санала;

б) гаризаны тиешле булмаган районның гомуми белем бирү оешмасына тапшыру;

в) укучыда (укучыларда) ташламалы туклануга хокук булмау.

4.7. Гариза бирүчеләргә гомуми белем бирү оешмасы (гариза составы мәгариф идарәсе акты белән төзелгән комиссия тарафыннан каралса, Мәгариф идарәсе тарафыннан,) комиссия әгъзалары кул куйган көннән соң 3 эш көне дәвамында комиссия беркетмәсе бирелә (җибәрелә).

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Районның гомуми белем бирү оешмасы:

- 2.4.5.2409-08 СанПиНны һәм закон нигезендә мәҗбүри булган башка таләпләрне үтәүне тәэмин итә;
- комиссия төзи һәм комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар булдыра;
- гаризалар кабул итүне тәэмин итә;
- районның гомуми белем бирү оешмаларында туклану мәсьәләләре буенча мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем өчен бу мәгълүматны алу мөмкинлеген тәэмин итә;
- ташламалы туклану бирелгән укучыларны, ташламалы туклану бирелә торган көннәрне һәм һәр укучыга фактта бирелгән ташламалы туклану күләмен исәпкә алып баруны тәэмин итә;
- Башкарма комитетка хокуксыз, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлы документлар тапшыру, ташламалы туклану алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү, хисап хаталары нәтиҗәсендә ташламалы туклану алган (алучы) укучылар турында һәм гариза бирүчеләр үзләре турында язма мәгълүмат җибәрә;
- Мәгариф идарәсе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктындагы дүртенче абзацында каралган вазыйфаларны үтәү өчен кирәк булган мәгълүматны Мәгариф идарәсенә җибәрә (тапшыра).

5.2. Мәгариф идарәсе түбәндәгеләрне башкара:

- компетенция кысаларында гомуми белем бирү оешмаларына, туклануны оештыру һәм ташламалы туклану хокукын тәэмин итү максатларында, кирәкле ярдәм күрсәтә;

- әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктындагы дүртенче абзацында каралган очракта комиссия төзи; мондый комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле шартларны тәэмин итә;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә ЕГИССОны куллану юлы белән районның гомуми белем бирү оешмаларында ташламалы туклану турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә;

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәгълүмат белән тәэмин итүче башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.3. Башкарма комитет түбәндәгеләрне башкара:

- оешмалардан мәгълүмат бирү турында соратулар җибәрү кирәклеге турында, ЕГИССОдан мәгълүмат бирү турында соратулар җибәрү кирәклеге турында комиссиянең тәкъдимнәрен карау нәтиҗәләре буенча тиешле мөрәҗәгатьләр җибәрә; күрсәтелгән соратуларга килгән җавапларны соратулар җибәрү кирәклеге турында тәкъдим кергән комиссиягә җибәрә;

- районның гомуми белем бирү оешмаларыннан килгән хокуксыз ташламалы туклану алган (алучы) укучылар турында мәгълүматларны карау йомгаклары буенча хокуксыз ташламалы туклану алган (алучы) укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына мондый укучыларны ташламалы туклландыруга тотылган чыгымнарны каплау турында таләпләр белән һәм суд органнарына мондый чыгымнарны укучыларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) түләтү турында дәгъвалар белән мөрәҗәгать итә.

5.4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының финанс-бюджет палатасы кирәкле ярдәм күрсәтә:

- районның гомуми белем бирү оешмаларына ташламалы туклану күләмен исәпләү максатларында;

- Башкарма комитетка әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән чыгымнар күләмен нигезләү максатларында.

5.5. Гариза бирүчеләр тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук әлеге беләшмәләр булган документларның чынлыгы өчен җаваплы.

5.6. Ташламалы туклану бирелгән укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) районның гомуми белем бирү оешмасына ташламалы туклану бирүне туктатуга китерә торган шартлар турында, мондый хәл килеп туган мизгелдән бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

5.7. хокуксыз, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлы документлар тапшыру, ташламалы туклану алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү, хисап хаталары нәтиҗәсендә ташламалы туклану алган (алучы) укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына ташламалы туклануга тотылган чыгымнарны капларга тиеш.

5.8. Ташламалы туклану бирүне туктатуга китерә торган шартлар туганда, ташламалы туклану әлеге шартлар туган айдан соң килүче айның беренче

числосыннан, ә ташламалы туклануны хокуксыз алу очракларында – әлеге шартлар билгеләнгән көннән туктатыла,

5.9. Ташламалы туклануны туктату турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан үз инициативасы буенча да, укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) мөрәҗәгатьләре нигезендә дә, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән һәм башка оешмалардан кергән мәгълүмат нигезендә дә карала.

Комиссия тарафыннан ташламалы туклануны туктату турындагы мәсьәләне караганда, комиссия әлеге Нигезләмәнең 4.3-4.5 пунктларында күрсәтелгән срокларны үтәүне тәэмин итә.

Ташламалы туклануны туктату турында комиссия карары комиссия әгъзалары тарафыннан тиешле беркетмәгә кул куелганнан соң 3 эш көне эчендә аларга карата мондый карар кабул ителгән укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) бирелә (җибәрелә). Шулай ук әлеге карарны комиссия район гомуми белем бирү оешмасының администрациясенә һәм ашханәсенә, район гомуми белем бирү оешмасының тиешле хезмәткәрләренә җиткерә.

5.10. Гариза бирүчеләр комиссия карарына суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5.11. Гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар тапшырылган затлар «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль законда каралган шәхси мәгълүматларны эшкәртү принципларын һәм кагыйдәләрен, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктының җиденче абзацында каралган хокукны комиссия тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибендә дә үтәргә бурычлы.

5.12. Әлеге нигезләмәнең 2.5 пунктының җиденче абзацында каралган хокукны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә шәхси мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыручы зат (алга таба әлеге пунктта – оператор кушуы буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүне башкаручы зат) тарафыннан башкарылачак шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр (операцияләр) исемлеген билгеләү: түбәндәге гамәлләрдән тыш, автоматлаштыру чараларын кулланып яисә шәхси мәгълүматлар белән мондый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасы:

- шәхси мәгълүматларны Башкарма комитеттан, район мәгариф идарәсеннән һәм гариза бирелгән гомуми белем бирү оешмасыннан тыш бүтән затларга һәм закон нигезендә шәхси мәгълүматларны алу хокукына ия башка затларга тапшыру (тарату, бирү, керү мөмкинлеге бирү);

- районның ташламалы туклану турында гариза бирелгән гомуми белем бирү оешмасы ризалыгыннан башка шәхси мәгълүматларны зарарсызландыру (обезличивание);

- районның гариза бирелгән гомуми белем бирү оешмасы рөхсәтеннән башка шәхси мәгълүматларны юк итү һәм юкка чыгару.

Оператор кушуы буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатлары: нигезләмәнең 2.6 пунктында каралган гаиләдә аз тәэмин ителеш турында шартларның булуын (булмавын) билгеләү.

Оператор кушуы буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүне башкаручы зат шәхси мәгълүматларның конфиденциальлеген (яшеренлеген) сакларга һәм аларны эшкәрткәндә шәхси мәгълүматларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиеш.

Оператор кушуы буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүне башкаручы затлар өчен мәҗбүри булган шәхси мәгълүматларны саклауга карата таләпләрне билгеләргә:

- шәхси мәгълүматларны хокуксыз яки очраклы рәвештә алардан файдалану, юк итү, ябу, блоктровкалау, күчерү, бирү, тарату өчен кирәкле хокукый, оештыру һәм техник чаралар күрү яки хокуксыз я очраклы рәвештә аларга керү мөмкинлегеннән, юк итү, үзгәртүдән, блокировкалаудан, күчермәләүдән, бирүдән, таратудан, шулай ук шәхси мәгълүматларга карата башка законсыз гамәлләрдән саклау өчен ул чараларны кабул итүне тәэмин итү;

- шәхси мәгълүматларның мәгълүмати системаларында эшкәрткәндә шәхси мәгълүматларга куркынычсызлык тудырылуын билгеләү;

- үтәлеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән шәхси мәгълүматларны саклау дәрәҗәсен тәэмин итә торган шәхси мәгълүматларны саклауга карата таләпләрне үтәү өчен кирәкле шәхси мәгълүматларның мәгълүмат системаларында эшкәрткәндә аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән шәхси мәгълүматларның иминлеген тәэмин итү буенча оештыру һәм техник чаралар куллану;

- туры килү-килмәүне бәяләү процедурасын билгеләнгән тәртиптә узган мәгълүматны саклау чараларын куллану;

- шәхси мәгълүматларның мәгълүмат системасын файдалануга керткәнче шәхси мәгълүматларның иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

- шәхси мәгълүматларны саклау чараларын (машинных носителей) исәпкә алу;

- шәхси мәгълүматка рөхсәтсез керү фактларын ачыклау һәм чаралар күрү;

- аларга рөхсәтсез керү нәтиҗәсендә модификацияләнгән яки юкка чыгарылган шәхси мәгълүматларны торгызу;

- шәхси мәгълүмат системасында эшкәртелә торган шәхси мәгълүматларга керү кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук шәхси мәгълүматлар мәгълүмат системасында шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган барлык гамәлләрне теркәү һәм исәпкә алуны тәэмин итү;

- персональ мәгълүматлар иминлеген тәэмин итү һәм шәхси мәгълүматларның мәгълүмат системаларының сакланышы дәрәҗәсен тәэмин итү буенча күрелә торган чараларны контрольдә тоту;

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль законның 19 маддәсе нигезендә башка таләпләр.

**Эшләр идарәчесе вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Якупов**

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районының гомуми белем
бирү оешмалары укучыларының
туклануын оештыру тәртибе турында
нигезләмәгә Кушымта №1

____________________________________
(муниципаль гомуми белем бирү
____________________________________
оешмасының исеме,
директоры ______________________________
җитәкченең фамилиясе һәм инициаллары)
____________________________________

____________________________________
(ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме,

____________________________________
әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта)

____________________________________
шәхси исәп-хисап счеты иминият номеры
(СНИЛС)
____________________________________
фактик яшәү урыны адресы:
____________________________________

____________________________________
(тулы адрес, телефон)
Җавап җибәрү өчен почта адресы:
____________________________________
____________________________________
____________________________________

ГАРИЗА

Сездән ____________________________________________________________
(муниципаль гомуми белем бирү оешмасы исеме)
______ сыйныф укучысы ____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына бушлай туклану бирүегезне сорыйм.

Гаилә әгъзасының җан башына уртача керем _______________________ сум тәшкил итә.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәм:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Бу гаризада бәян ителгән мәгълүматларның чынлыгы һәм дөреслеге өчен тулы җаваплылык тотам.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының ___________ел, № ___________ карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән таныштым.

Кушып бирелә торган документлар исемлеге:

"_____" _____________20____ ел ________________________
(подпись)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәгә Кушымта № 2

______________________________
(муниципаль гомуми белем бирү
______________________________
оешмасының исеме,
______________________________
җитәкченең фамилиясе һәм инициаллары)
______________________________

______________________________
(ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме,

______________________________
этисенең исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________

______________________________

фактик яшәү урыны адресы:
______________________________

______________________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин, ______________________________________________________________,
фамилиясе, исеме, этисенең исеме (соңгысы – булган очракта
«Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль законның 9 маддәсе нигезендә түбәндәге адрес буенча теркәлдем:
______________________________________________________________________,
шәхесне раслаучы документ:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(документның исеме, №, документ бирү датасы һәм
______________________________________________________________________
аны биргән орган турында белешмәләр)
бушлай туклану бирү турындагы гаризаны карау максатларында
______________________________________________________________________
(баланың (балаларның) фамилиясе, исеме, этисенең исеме (соңгысы – булган очракта) (детей))
______________________________________________________________________

һәм социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында, федераль, төбәк, муниципаль регистрларда, социаль яклау (ярдәм) өлкәсендә башка дәүләт һәм төбәк мәгълүмат системаларында һәм түләүсез туклану бирү турында югарыда күрсәтелгән гариза бирелгән гомуми белем бирү оешмасының мәгълүмат системасында норматив хокукый актларда каралган мәгълүматны урнаштыру максатларында

ризалык бирәм ______________________________________________________
(муниципаль гомуми белем бирү
______________________________________________________________________,
оешмасы исеме)

шәхси мәгълүматларны эшкәртү йөкләнгән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына, башка затларга

минем шәхси мәгълүматларны һәм минем тарафтан аларга карата гариза бирелгән баланың (балаларның) шәхси мәгълүматларын (фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, яшәү адреслары, паспорт мәгълүматлары һәм гаризада билгеләнгән һәм аңа кушып бирелгән документлар /күчермәләрендә күрсәтелгән башка шәхси мәгълүматларны) эшкәртүгә, шул исәптән әлеге мәгълүматларны дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә тапшыру өчен, ягъни автоматлаштыру чараларын кулланып яисә шәхси мәгълүматлар белән мондый чараларны кулланмыйча башкарылучы, шул исәптән җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), шәхси мәгълүматларны зарарсызлау (обезличивание),

блокировкалау, бетерү, юк итү кебек теләсә нинди гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасын башкаруга.

Әлеге килешүнең гамәлдә булу вакыты: сроксыз. Әлеге килешүне кире алу ысулы: гариза бирүче тарафыннан имзаланган язма хәбәр (хәбәрнамә).

"__" ________ ____ ел ________________________________________________________

(шәхси мәгълүматлар субъектының имзасы)